КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 июнь г.Казань № 608

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «, 2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 елда бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «, 2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «, 2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бөртекле культуралар - бодай, арыш, кукуруз, арпа. Күрсәтелгән культуралар бодай өчен ГОСТ 9353-2016 һәм ГОСТ 54078-2010, арыш өчен - ГОСТ 16990-2017 һәм ГОСТ 54079-2010, терлек азыгына арпа өчен - ГОСТ 28672-2019 һәм ГОСТ Р 53900-2010, кукуруз өчен - ГОСТ 13634-90 һәм ГОСТ Р 53903-2010 туры килергә тиеш;»;

3 пунктның икенче абзацында «кайтару буенча» сүзләрен «, кайтарганда барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://agro.tatarstan.ru сайтында (алга таба - рәсми сайт) сайлап алуны үткәрү вакыты башланганчы өч календарь көннән дә соңга калмыйча сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән көннең иртәгесеннән алдагы 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итә башлау яисә тәгәлләү датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң килүче 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

Министрлыкның һәм аның Татарстан Республикасы тиешле муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемнәрен, урнашу урыннарын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.»;

7 пунктта:

икенче абзацка «(2022 елда сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган башкарылмаган бурычы булырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә, йә аларга карата массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел;

2022 елда сайлауда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яисә Россия юридик затларына карата дустанә булмаган гамәлләр кылучы чит дәүләтләр тарафыннан сәяси яисә икътисадый санкцияләр кертелү сәбәпле һәм (яки) чит дәүләтләр, дәүләт берләшмәләре һәм (яисә) союзлар һәм (яисә) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләр яисә дәүләт берләшмәләре һәм (яисә) чикләнгән характердагы чаралар берлекләре кертү белән бәйле бу товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турындагы төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тарту белән бәйле намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булырга тиеш түгел.»;

8 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмауны раслый торган салым органы белешмәсен (мондый документны сайлауда катнашучы тарафыннан тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала) яки 2022 елда сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән 300 мең сумнан артмаган үтәлмәгән бурыч булуын раслый торган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлары буенча исәп-хисаплар торышы турында салым органы белешмәсен;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз производствосының җитештерү күләмнәре һәм аларны агымдагы елның гыйнварыннан июньгә кадәр сату турында белешмәләр;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз производствосының бөртекле культураларын агымдагы елның гыйнварыннан июнь аена кадәр сату фактын раслый торган документлар (килешүләр (агентлык килешүеннән тыш, арадашчы хезмәтләр күрсәтмичә), товар-транспорт накладнойлары һәм (яисә) универсаль тапшыру документлары, сатылган продукциягә түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре);»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Идарә:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкалар кабул итү срогы эчендә заявкаларны, аларның керү датасын һәм кергән көндәге вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган формаларда бирелергә сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән критерийларга туры килүгә документлар реестрын, җыелма белешмә-исәп формалаштыра, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында реестр формалаштыра һәм аларны Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Министрлыкка җибәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$. Министрлык:

реестрлар Идарәләре тарафыннан тапшырылган реестрлар нигезендә заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча заявкалар бирү чиратлылыгы тәртибендә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү йә гаризаны кире кагу турында) җыелма реестр төзи һәм раслый;

сайлап алу җиңүчеләрен билгеләгән көннән соң 14 нче календарь көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда һәм рәсми сайтта түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.»;

11 пунктның сигезенче абзацына «(2022 елда килешүләрнең яңа шартларын килештерү тәртибе, шул исәптән, әгәр күрсәтелгән орган килешү ягы булмаса, дәүләт сәясәтен эшләү һәм эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы вәкилләре катнашында да кирәк булганда.)» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык субсидия алучыларга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган Идарәләрнең шәхси счетларына үз шәхси счетларыннан акча күчерә.»;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$ Идарәләр бюджет акчасы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси счетына кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә

торган биш көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучылар өчен ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

14 пунктта:

алтынчы абзацта «2021 елда» сүзләрен «агымдагы елның гыйнварыннан июнь аена кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «2021 елда» сүзләрен «агымдагы елда» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $14^1$ пункт өстәргә:

«$14^1$. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның бу Тәртипнең 8 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Агымдагы елның 30 июнендә үзендә җитештерелгән бөртекле культуралар күләме (мең тоннага) субсидия бирү нәтиҗәсе булып тора.

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән нәтиҗәнең һәм агымдагы елның 30 июненә субсидияләр бирүнең торышы буенча ирешелгән күрсәткечнең мәгънәсен чагыштыру нигезендә бәяләнә.

2022 елда килешү белән билгеләнгән срокларда субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган хәлләр барлыкка килгән очракта, Министрлык субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә генә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын озайту өлешендә (әмма 24 айдан артмаган вакытка) килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия бирү нәтиҗәсенә субсидия күләмен үзгәртмичә ирешү мөмкин булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.»;

17 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

18 пунктта:

беренче абзацта «2021 ел» сүзләрен «агымдагы ел» сүзләренә алмаштырырга, «2022 ел» сүзләрен «субсидия бирү елыннан соң килүче ел,» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Министрлык субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле 20[1] пункт өстәргә:

«20[1]. Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларның күрсәткечләренә ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләр буенча мониторинг үткәрү.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 07 сентябрь, 836 нчы карары белән расланган 2021 елда федераль бюджеттан финанслана торган бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан бөртекле культуралар җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенең 7 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының җитмеш бишенче абзацыннан тыш.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин